**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

28.11.2022 1138-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 23 августындагы 731-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гобәдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2022 елның 28 ноябрендәге
1138-п номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3.1 пунктының икенче, өченче һәм дүртенче абзацларында «норматив-хокукый характердагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы.

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәреп яисә шәхсән тапшырылган булса, дәүләт хезмәте гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 24 көнлек чорда күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталындагы шәхси кабинеты аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә Республика порталындагы шәхси кабинетта (алга таба – шәхси кабинет) күренә торган номер һәм "Документларны тикшерү" статусы беркетелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 24 көнлек чорда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына (24 эш көне) эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар-саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, туктату турында норматив хокукый характердагы боерык рәвешендә рәсмиләштерелгән карарны дәүләт теркәвенә алу срогы кертелми.

Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турындагы карар мөрәҗәгать итүчегә норматив хокукый характердагы боерык үз көченә кергән көннән алып 3 эш көне эчендә бирелә (җибәрелә).»;

2.6.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.6. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

санитар саклык зонасы проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе яки санитар саклык зонасы чикләренең һәм мондый зоналарда җир кишәрлекләреннән файдаланудагы чикләүләрнең санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе – Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсеннән;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән санитар саклык зонасының беренче поясы астындагы җир кишәрлегенә милек хокукын, файдалану яисә арендалау хокукын раслаучы белешмәләр – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә дә тапшырырга хокуклы.»;

2.8.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гаризада һәм аңа беркетелгән документларда дөрес булмаган яки үзгәртелгән мәгълүмат булу;»;

бишенче абзацта «әлеге Регламентның 5 пункты» сүзләрен «Регламентның 2.6 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.5.2. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләрне әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, сорала торган документлар исемлеге:

санитар саклык зонасы проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмәнең күчермәсе яисә санитар саклык зонасы чикләренең һәм мондый зоналар чикләрендәге җир кишәрлекләренең санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмәнең күчермәсе. Рәсми мөрәҗәгать Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә җибәрелә»;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән санитар саклык зонасының беренче поясы астындагы җир кишәрлегенә милек хокукын, файдалану яисә арендалау хокукын раслаучы белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрелә.

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

3.5.4. Әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.5.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.6 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне –дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш.

Регламентның 3.5.4, 3.5.5 пунктларында күрсәтелгән административ процедураларның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яки ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерү тора.

3.5.6. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратып алына торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаса, баш тарту турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча белешмәләр алынган көнне үтәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән гарызнамәләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне кулланунын максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.5.7. Регламентның 3.5.2 пунктчасында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, шул исәптән гаризаны теркәгән вакыттан башлап, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.";

3.6 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.7.1 пунктта:

беренче абзацта «3.5 һәм 3.6 пунктлары» сүзләрен «3.5 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

өченче һәм бишенче абзацта «норматив-хокукый характердагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.7.8 пунктында «норматив-хокукый характерда» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.8 пунктта «норматив-хокукый характерда» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.9.2 пунктта «норматив-хокукый характерда» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.10 пунктының икенче абзацында «норматив хокукый характерда» сүзләрен төшереп калдырырга.